ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУРКУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЫРКУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2026 № 5

с.Куркуль

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында » 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынына туры китереп, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карарын игътибарга алып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге Башкарма комитетының 21.06.2021 ел, № 7 «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге Башкарма комитетының 05.07.2021 ел, №9 «Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Кыркул авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **М.Р.Афанасьева**